УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.12.2021 Казан шәһәре № 01-05/323 - пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 20 статьясы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы указының 2 пункты нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан

хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 11 августындагы 01-05/205-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

Башлык Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Дәүләт техник күзәтчелек
идарәсенең 15.12.2021
№ 01-05/323-пр боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның иң югары төркемендәге вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе җитәкчесе.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның төп төркемендәге вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе җитәкчесе урынбасары.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең районнардагы, шәһәрләрдәге бүлекләре җитәкчеләре;

оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге җитәкчесе;

икътисадый анализ, эшчәнлекне тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары бүлеге җитәкчесе;

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлеге җитәкчесе;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юллардан йөри торган транспортка дәүләт контроле бүлеге җитәкчесе.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең районнардагы, шәһәрләрдәге бүлекләре консультантлары;

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлегендә әйдәп баручы киңәшче;

мобилизация эше буенча әйдәп баручы киңәшче;

икътисадый анализ, эшчәнлекне тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юллардан йөри торган транспортка дәүләт контроле бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, 2 штат берәмлеге.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

икътисадый анализ, эшчәнлекне тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары бүлегенең әйдәп баручы белгече;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юл транспортына дәүләт контроле бүлегенең әйдәп баручы белгече;

оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы белгече – коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның өлкән төркемендәге вазыйфалары:

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

икътисадый анализ, эшчәнлекне тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече, 2 штат берәмлеге.